ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 520-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

А.В. Тыгин тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен башкарган чорда кертелгән «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 520-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2346-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.В. Тыгин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $10^{11}$ һәм $10^{12}$ пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«$10^{11}$) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик затны билгеләү;

$10^{12}$) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителә торган территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 71 статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән килешүне төзү очракларын, килешүнең эчтәлеген, аны төзү һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;».

**2 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан

Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), «дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә» сүзләреннән соң «йә, торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү хакындагы килешүдә каралган булса, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат милкенә» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында эшләнде.

Югарыда аталган Федераль закон белән территорияләрне комплекслы үстерү турында шартнамәләр төзелгән затларның һәм территорияләрне комплекслы үстерү турында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик затларның хокукларын һәм бурычларын билгели торган шәһәр төзелеше һәм торак законнарын камилләштерү каралган. Аерым алганда, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына Россия Федерациясе яисә Россия Федерациясе субъекты тарафыннан билгеләнгән һәм территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат булган территорияне комплекслы үстерү операторы төшенчәсе кертелде.

Закон проекты белән «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә территорияне комплекслы үстерү операторын билгеләү, шулай ук мондый оператор белән территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатларында вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы белән килешү төзү тәртибен билгеләү каралган тиешле үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр белән торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыручы юридик затның милкенә мондый территория чикләренә кертелгән күпфатирлы йортлардагы урыннарны тапшыру мөмкинлеге карала.

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә законнарның үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителә торган территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 71 статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән килешүне төзү очракларын, килешүнең эчтәлеген, аны төзү һәм гамәлгә ашыру тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.